| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ**<br>от 29 июня 2016 г. | г. Казань | **БОЕРЫК**<br>№ 164 |

**2015 елның 9 ноябрендәге 332 санлы Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлүче электр челтәрләренә техник тоташтырган өчен түләү һәм (яисә) аның зурлыгын билгеләү өчен тәгаенләнгән тариф ставкаларын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) куллану белән бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында.**

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) норматив хокукый актын законга туры китерү максатыннан

б о е р а м:

1. 2015 елның 9 ноябрендәге 332 санлы Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлүче электр челтәрләренә техник тоташтырган өчен түләү һәм (яисә) аның зурлыгын билгеләү өчен тәгаенләнгән тариф ставкаларын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) куллану белән бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.4 пунктының «Стандартка таләпләрнең эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Гаризаны карау өчен кабул итү яисә гаризаны караудан баш тарту турындагы карарны Регламентның 2.5, 2.6 пунктларында каралган документларының кергән мизгелдән алып 10 эш көне дәвамында кабул итергә.

Гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулаем яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында яисә таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында нигезле карарны гаризаны кабул иткән көннән алып 90 көн эчендә кабул итергә.

Бәхәсләрне карау нәтиҗәләре буенча чыгарылган карарны 5 эш көне эчендә кызыксынган якларга җибәрү.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату вакыты (бәхәсләрне карау) өстәмә мәгълүматлар алу яисә бәхәсне карауга башка затларны җәлеп итү һәм (яисә) экспертиза уздыру таләп ителгән очракта карар кабул ителгән көннән алып 60 көннән артып китә алмый.

Күрсәтелгән вакытны кабат туктату рөхсәт ителми».

2.5нче пунктында «Стандарт таләпләре эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә.

«Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын Дәүләт комитетына шәхси мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны һәм беркетелгән документларны гариза бирүче кәгазь формасында түбәндәге ысуллар белән бирә (җибәрә) ала: шәхси (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән башка зат);

Тапшыру турында уведомлениеле заказлы почта хаты аша.

Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле имза белән электрон формада гомуми информацион-телекоммуникация һәм шул исәптән «Интернет» информацион-телекоммуникация челтәрләре аша бирелергә (җибәрелергә) мөмкин;

2.6нчы пунктында «Стандарт таләпләре эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә;

«Гариза бирүченең документлар бирү тәртибе һәм алу ысуллары әлеге Регламентның 2.5нче пункты белән билгеләнгән.

Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда әйтелгән документларны таләп итү тыелган».2.8 графада «Стандартка таләпләрнең эчтәлеге»н түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Документлар кабул итүдән баш тарту нигеләре каралмаган»;

2.14 пунктында:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» бүлеген түбәндәге редакцияда бәян итергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләр өчен көтеп тору һәм аларны кабул итү урынына, шулай ук Россия Федерациясе инвалидларны социаль яклау турында законы нигезендә күрсәтлегән объектларда инвалидлар өчен кереп-йөрү мөмкинлекләрен булдыруга, хезмәт күрсәтүләр тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мульти-медиа мәгълүматларын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр»;

«Стандартка таләпләрнең эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

Дәүләт хезмәте түбәндәге рәвештә җиһазландырылган бүлмәләрдә күрсәтелә:

һаваны җилләтү системасы;

янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы;

документлар рәсмиләштерү өчен җиһазлар;

мәгълүмати стендлар.

Инвалидлар дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга каршылыксыз үтә алу, шул исәптән объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу, шулай ук объект буенча хезмәт күрсәтү урынына үтү өчен мөстәкыйль йөрү мөмкинлеге белән тәэмин ителә.

Инвалидларга һәм мөмкинлекләре чикләнгән затларга дәүләт хезмәте яшәү урыны буенча яисә видеоэлемтә юлы белән интернет аша дистанцион режимда күрсәтелергә мөмкин.

Мәгълүматлар куелган эленмә такталары, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы мәгълүматлар Дәүләт комитетының төп керү урынында һәм гражданнар мөрәҗәгать итү бүлегенен гариза бирүчеләр өчен шулай ук мөмкинлекләре чикләнгән инвалирлар өчен уңайлы булган керү урынында эленгән мәгълүмати стендларга урнаштырылган»;

2.15 пуктында «Стандартка таләпләрнең эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац белән тулыландырырга:

«4) инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүне комачаулаучы киртәләрне үтүдә ярдәм күрсәтү.»;

11-12 абзацларын 12-13 абзацлар дип исәпләргә;

3 бүлектә:

3.4 пунктын түбәндәге пунктча белән тулыландырырга:

«3.4.2. Мәгълүмат бирүче белгечләр ведомствоара электрон аралашу системасы аша килгән запрослар нигезендә соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат булмау турында уведомление бирәләр яисә җибәрәләр (алда – баш тарту турында уведомление).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар документ һәм мәгълүмат бирүче органга яисә оешмага ведомствоара запрос килгән көннән алып биш көн эчендә башкарыла, әгәр дә ведомствоара запроска җавап бирү вакыты федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнарга ярашлы рәвештә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

Прцедуралар нәтиҗәсе: соралган белешмәләр, яисә Бүлеккә җибәрелгән баш тарту турында уведомление.»;

3.5.5.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Бүлек белгече, гаризаны карап тикшерү буенча кабул ителгән карарны алгач, түбәндәгеләрне башкара:

технологик тоташтыру өчен түләү кулланууның дөреслеген тикшерә;

Дәүләт комитетының юридик бүлегенә әлеге утырыш кысаларында карала торган бәхәскә кагылышлы материалларны юнәлдерергә;

бәхәсне карап тикшерү буенча киңәшмәне үткәрү көне, вакыты һәм урыны турында якларга телефон элемтәсе аша, яисә якларның адресларына факсограмма юнәлтеп, хәбәр итү;

киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы булган белгечкә гариза бирүченең гаризасын, документларын, барлыкка килгән бәхәс буенча бәяләмәләрне, карап тикшерү турындага гаризаны кабул итү турындагы карарны юнәлтү;

әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган мизгелдән алып ике көн эчендә, бәхәсне карап тикшерү көненә кадәр 5 көн кала гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: бәхәсне карап тикшерү буенча киңәшмәне үткәрү көне турында якларга һәм юридик бүлек белгечләренә хәбәр итү; киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы булган белгечкә юнәлтелгән материаллар.»;

3.5 пунктын тхбәндәге эчтәлекле пунктча белән тулыландырырга:

«Бүлек белгече экспертиза нәтиҗәсе алгач әлеге Регламентның 3.5.5нче пунктында каралган процедураларны башкара.»;

3.5.8 – 3.5.9 пуктчаларын 3.5.9 – 3.5.10 пунктчалары дип исәпләргә;

3.7.1 пунктчаының икенче абзаөы төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.8 пунктчасы белән тулыландырырга:

«Гариза бирүчеләргә күпфункцияле үзәктә, еракта булган эш урынында дәүләт хезмәте күрсәтү.

Күпфункцияле үзәк аша дәүләт хезмәте, эш урыны еракта булган күпфункцияле үзәктә күрсәтелми»;

3.8, 3.8.1, 3.8.2, 3.8.3 пунктларын 3.9, 3.9.1, 3.9.2, 3.9.3 пункталры дип исәпләргә ;

3.8.2 пунктчада:

Текстка түбәндәге эчтәлектәге икенче яңа текст өстәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза бирелгән көнне башкарыла.»;

икенче абзацны өченче абзац дип исәпләргә;

5 бүлектә:

5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта, күпфункцияле үзәк буенча, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән, Интернет – кабул итү төреннән, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, күпфункцияле үзәк аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.»;

Түләү күләмен (стандартлаштырылган тариф ставкалары) билгеләү өчен территориаль бүленеш электр челтәренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик кушу өчен түләү куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәтләре тарифлары буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты бирелгән административ регламентка 2нче кушымтасын әлеге боерык кушымтасы нигезендәге редакциядә бәян итергә;

кушымтаны (мәгълүмати) түбәндәге эчтәлекле таблица белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетында җавап бирүче вазифаи затның реквизитлары


| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе начальнигы | 8(843) 264-77-22 | Renat.Gaynutdinov@tatar.ru » |


2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн үткәч үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольда тотуны Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының рәисенең беренче урынбасары А.Л. Штромга тапшырырга.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты боерыгына
29.06.2016 № 164
Кушымта






Шундый түләү зурлыгын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) билгеләү өчен куелган, территориаль бүленеш электр челтәренә һәм (яисә) тариф ставкаларына технологик кушу түләүләрен куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү рәсеме – блок-схемасы.